ГЛАВА
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.02.2021 п.г.т. Алексеевское № 11

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында СПИД-ВИЧны профилактикалау һәм аңа каршы көрәш буенча ведомствоара комиссия төзү турында**

Район халкының иммунодефицит вирусы (ВИЧ-инфекция) белән авыруын тагын да киметү, хәвеф-хәтәр төркемнәрендә һәм район халкы белән профилактик эшне көчәйтү, үткәрелә торган чаралар комплексының нәтиҗәлелеген арттыру һәм «Россия Федерациясендә Кеше иммунодефициты вирусы (ВИЧ-инфекция) китереп чыгаручы авыруларның таралуын кисәтү турында» 1995 елның 30 мартындагы 38-ФЗ номерлы Федераль законны, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2001 елның 11 сентябрендәге 635 номерлы «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы һәм аның составындагы СПИДка каршы көрәш ведомствоара комиссиясе турындагы нигезләмәне раслау хакында» карары үтәлешен тәэмин итү максатларында

**карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында СПИД-ВИЧны профилактикалау һәм көрәшү буенча Ведомствоара комиссия төзергә.
2. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында СПИД-ВИЧны профилактикалау һәм көрәшү буенча Ведомствоара комиссия составын расларга (1 нче кушымта).
3. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында СПИД-ВИЧны профилактикалау һәм аңа каршы көрәш Ведомствоара комиссиясе турындагы Нигезләмәне расларга (2 нче кушымта).
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.В. Симашевага йөкләргә.

**Алексеевск муниципаль районы башлыгы** **С.А.Демидов**

Татарстан Республикасы Алексеевск
муниципаль районы башлыгының
2021 елның 10 февралендәге
11 номерлы карарына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында СПИД-ВИЧны профилактикалау һәм көрәшү буенча Ведомствоара комиссия составы**

| | |
|---|---|
| 1. Демидов С.А. | - комиссия рәисе, Алексеевск муниципаль районы башлыгы |
| 2. Симашева А.В. | - комиссия рәисе урынбасары, башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары |
| 3. Галиев А.Т. | - комиссия сәркатибе, Алексеевск РҮХ эпидемиологик мәсьәләләр буенча баш табибы урынбасары (килешү буенча) |
| 4. Леденцов О.Н. | - Алексеевск муниципаль районының финанс-бюджет палатасы рәисе |
| 5. Вилданов И.Х. | - «Алексеевск РҮХ» ДАССУ баш табибы (килешү буенча) |
| 6. Кирюхина Л.Н. | - тәрбия эшләре буенча «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ башлыгы урынбасары |
| 7. Әхмәтҗанов Р.Р. | - РТ буенча Россия Эчке эшләр министрлыгының Алексеевск районындагы бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| 8. Хөснетдинов Р.Р. | - РТ буенча Чистай районында һәм Чистай шәһәрендә Россия кулланучылар күзәтчелеге идарәсенең территориаль бүлеге башлыгы урынбасары (килешү буенча) |
| 9. Әхмәтова Г.Х. | Татарстан Республикасы Алексеевск |

районындагы Россия Федерациясе Пенсия фонды идарәсенең клиент хезмәте җитәкчесе (бүлек хокукларында) (килешү буенча)

| | |
|---|---|
| 10. Хәмзина Е.А. | Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль яклау бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| 11. Монина И.Ю. | - «Заря», «Таң» район газетасының баш мөхәррире (килешү буенча) |

**Совет аппараты җитәкчесе** **А.С.Харитонов**

Татарстан Республикасы Алексеевск
муниципаль районы башлыгының
2021 елның 10 февралендәге
11 номерлы карарына
2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы
СПИД-ВИЧ белән көрәш буенча ведомствоара комиссия турында
НИГЕЗЛӘМӘ**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының СПИД-ВИЧка каршы көрәш буенча Ведомствоара комиссиясе (алга таба-Комиссия) Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы халкы арасында кеше иммунодефициты вирусы (СПИД, ВИЧ) профилактикасына һәм аңа каршы көрәшкә юнәлдерелгән бурычларны хәл итүдә кызыксынган учреждениеләрнең һәм оешмаларының килешеп эшләвен тәэмин итүче координацион орган булып тора.

2. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларына һәм күрсәтмәләренә, Россия Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм башка федераль башкарма хакимият органнарының карарларына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарларына, Татарстан Республикасы Президенты указларына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә һәм башка норматив актларга таяна.

3. Комиссиянең төп бурычлары булып тора:

- Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә кеше иммунодефициты вирусы (ВИЧ/СПИД) профилактикасы һәм аңа каршы көрәш өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыруны тәэмин итү буенча чаралар эшләү;

- кеше иммунодефициты вирусы (ВИЧ/СПИД) профилактикасы һәм аңа каршы көрәш өлкәсендә кызыксынучы учреждениеләр, предприятиеләр һәм оешмалар, шулай ук вазыйфаи затлар һәм гражданнар эшчәнлеген координацияләү;

- Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә СПИДны профилактикалау һәм аңа каршы көрәш буенча норматив актларны камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләү һәм билгеләнгән тәртиптә кертү.

4. Комиссия үзенә йөкләнгән бурычлар нигезендә түбәндәге функцияләрне башкара:

- кеше иммунодефициты вирусы (ВИЧ/СПИД) белән бәйле эпидемиологик процессның үсешен бәяли;

- Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә озак вакытка исәпләнгән комплексле чараларны эшли һәм контрольдә тота;

- ведомствоара чараларны тормышка ашыру процессын эшли һәм өйрәнә, килеп туган проблемаларны хәл итү буенча үз киңәшләрен бирә.

5. Комиссия хокуклы:

- Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы оешмаларыннан һәм учреждениеләреннән кеше иммунодефициты вирусы (ВИЧ/СПИД) белән авыруы турында, ВИЧ/СПИДны профилактикалау һәм аңа каршы көрәш өлешендә дәүләт сәясәтен үтәүнең барышы турында кирәкле мәгълүматны алырга;

- ВИЧ/СПИДны профилактикалау һәм аңа каршы көрәш, шул исәптән элегрәк кабул ителгән комиссия карарларын үтәү буенча чараларны гамәлгә ашыру турында Оешмалар һәм учреждениеләр җитәкчеләре, башка вазыйфаи затлар үз утырышларында тикшерүләр оештырырга, тыңларга.

6. Комиссиянең персональ составы һәм аның Рәисе Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы башлыгы тарафыннан раслана. Комиссия әгъзалары комиссия эшендә шәхсән катнашалар.

7. Комиссия утырышлары кирәк булган саен, әмма кварталга кимендә бер тапкыр үткәрелә.

8. Комиссия карары күпчелек тавыш белән кабул ителә һәм билгеләнгән форма буенча беркетмә белән рәсмиләштерелә. Тавышлар тигез булганда, Рәиснең тавышы хәлиткеч булып тора. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы башлыгы карарын таләп итә торган мәсьәләләр буенча Комиссия тиешле тәкъдимнәр кертә.

9. Комиссия эшчәнлеген оештыру-техник яктан тәэмин итү Татарстан Республикасының «Алексеевск үзәк район хастаханәсе» ДАССУ белән килештереп гамәлгә ашырыла.

**Совет аппараты җитәкчесе** **А.С.Харитонов**